| | | |
|---|---|---|
| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>ШӘҺӘР СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 февраль 2020 ел № 37/7

Шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 22 октябрендәге 2/11 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 5, 399 һәм 403 статьялары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 22 октябрендәге 2/11 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 21/8, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/7, 2019 елның 7 октябрендәге 33/7, 2019 елның 6 декабрендәге 34/8 номерлы Карарлары редакциясендә), 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган салым түләүчеләрне;

2)әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән салым түләүчеләрнең балаларын.

Салым ташламасы түбәндәге салым салу объектларына карата бирелә:

1) фатирлар, фатир яки бүлмә өлеше, торак йорт яки торак йорт өлеше;

2) гараж яисә машина кую урыннары, шул исәптән әлеге Карарның 2 пунктындагы 4, 5 пунктларында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан, мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган.

Салым ташламасы, салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә, гаиләгә туры килә торган һәр салым салу объекты төренә кергән бер обьектка карата салым түләүченең теләге белән бирелә.

Салым ташламасы яшәү урыны буенча теркәлү урыны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге булган салым түләүчеләргә салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган салым объектына карата салым суммасы күләмендә бирелә.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламалары хокукына ия физик затлар салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында белдерү салым түләүченең үз теләге белән салым органына үз теләге белән, әлеге объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган салым чоры булып торучы елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча тапшырыла.».

2. Әлеге Карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тоту Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш һәм бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев